ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

Капиталь төзелеш объектын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгы боерыгы проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү хакында

Югары Ослан районында яшәүчеләрнең җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларында яшәүчеләрнең тормыш шартлары, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү турындагы Нигезләмә нигезендә, гр. Җураева Н. А. мөрәҗәгатен карап

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Введенский Бистәсе авыл җирлеге, Введенский Бистәсе авылы, Урман ур., 6/2 җир кишәрлеге адресы буенча урнашкан кадастр номеры 16: 15: 040701: 92 булган 475 кв. м мәйданлы җир кишәрлеген капиталь төзелеш объекты төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән параметрларыннан чигенүгә рөхсәт бирү буенча төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты буенча Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Введенкский Бистәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең индивидуаль торак төзелеше (Ж1) зонасында «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану төре белән:

- җир кишәрлеге чикләреннән 1 нче ноктадан 2 нче ноктага кадәр – 0 м га кадәр; 2 нче ноктадан 3 нче ноктага кадәр – 0 м га кадәр минималь чигенешләрне киметү өлешендә (кушымта) иҗтимагый фикер алышуларны билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча җәмәгать фикер алышуларын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген (алга таба - җәмәгать фикер алышуларын оештыручы) билгеләргә.

3. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы – коллегиаль киңәшмә органы составын расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе А. Ә. Әхмәтшин;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. Д. Сәгъдиева;

-Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының оештыру-хокукый һәм кадрлар эше җитәкчесе Н.В. Пичугина;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов.

4. Җәмәгать фикер алышуларын оештыручыга җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә җәмәгать фикер алышуларын оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

5. Иҗтимагый фикер алышулар үткәрү чорын 2026 елның 14 гыйнварыннан 2026 елның 2 февраленә кадәр билгеләргә.

6. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 ст. нигезендә иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәр әзерләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында (https://verhniy-uslon.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

8. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е. А. Варакин